СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2019 ел** **№4**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Үгез-елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Үгез-Елга авылында Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2019 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Үгез-Елга авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау Үгез-елга авылы, Яшел урам-66 м?

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Үгез-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Үгез-елга авылы, Яшел урам, 4 йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов